ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 03 2021 г. № 75

Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең иң чик күрсәткечләрен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, әлеге законга кушымтада бәян ителгән гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм салым салынырга тиешле керемнең иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, карар бирәм:

1. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондында социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге иң чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.1.1. Ялгыз кеше өчен – 27 412,88 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 17 444,56 сум;

1.1.3. Өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 14 952,48 сум.

2. Гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының салым салынырга тиешле мөлкәте бәясен билгеләргә:

2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 1 949 904,00 сум;

2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2 481 696,00 сум;

2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 3 190 752,00 сум;

2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 4 254 336,00 сум;

2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 5 317 920,00 сум.

2. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең иң чик күрсәткечен билгеләү турында» 2020 елның 3 мартындагы 59 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге җитәкчесе Е.С. Митрошенковага йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Салаватов